# “ЖИР” КОНЦЕПТЫНЫҢ ТАБЫШМАКЛАРДА АССОЦИАТИВ-СЕМАНТИК ТӨРКЕМЕ

*Ф.ф.к. Хөснетдинов Д.Х.*

Борынгы чорларда ук барлыкка килүләренә карамастан, табышмаклар искергән мирас түгел. Алар тормышыбызда, сөйләмебездә яши. Табышмаклар – күп гасырлар дәвамында формалашкан гаҗәеп күренеш, аның аша буыннар аралашуы бара, алар ярдәмендә башка халыкларның фикер йөртү рәвешенә үтеп керергә, күпмедер күләмдә аның фикерләренең үзенчәлеген аңларга, холык-фигыленә төшенергә була. Шуңа күрә дә аларның асылын тикшерү-өйрәнү бик мөһим, чөнки әлеге жанр да ерак борынгылыкка барып тоташа һәм халкыбыз тормышы, көнкүреше, мәдәнияте белән тыгыз бәйле булган концептларны үзендә чагылдыра. Концептлар шул исәптән *җир* концепты да әлеге жанрда яңача яңгыраш алырга, халык тормышындагы яшерен каршылык һәм кыенлыкларны гәүдәләндерергә мөмкин. Ә җир төрки халыклар тормышында төп рольләрнең берсен уйнаган һәм матди, һәм мәдәни байлык. *Җир* лексемасының табышмакларда бирелешен анализлап, түбәндәге төркемнәрне аерып чыгарырга була.

1. "Җир – галәмнең бер өлеше" ассоциатив-семантик төркеме.

Күп кенә табышмакларда җир – бөтен җир йөзе, кайбер очракларда хәтта галәм буларак та күз алдына килергә мөмкин. Бу очракта ул иксез-чиксез, очсыз-кырыйсыз җир йөзе буларак күзаллана. Кайбер табышмакларда җир шары мәгънәсендә кулланыла һәм мәкальләрдәге кебек үк Күк белән янәшә килә, каршылык тудыра. Ә каршылык тудыру табышмакларга хас төп сыйфатларның берсе булып тора:

Күктә дә йөгерек,
*Җирдә* дә йөгерек,
Берсен дә узалмассың йөгереп (кояш, ай, йолдыз).

Шунысы кызык: күк җисемнәре белән бәйле булган табышмакларның барысында да диярлек җир күк белән каршы куела, яисә янәшә чагыштырып кулланыла. Ә менә табышмакның җавабында явым-төшем күтелсә, *җир* лексемасы башлыча *төшә, менә, килә, китә, ашкына, чылата* кебек предикатлар белән янәшә кулланыла:

Күктән килде, *җиргә* китте (яңгыр).

Табышмакларда еш очрый торган *җир өсте* сүзтезмәсе дә күп вакытта бөтен дөньяны күз алдына китерә:

Ак ашъяулык таптык, *җир өстенә* яптык (кар).

Югарыда китерелгән табышмакларда *җир, җир өсте* лексемалары ниндидер өстәмә мәгънә алып килмичә, үзләренең туры мәгънәләрендә кулланылган. Табышмакның җавабын бала яисә укучы нәкъ менә шушы *җир* сүзенә таянып эзләргә дә мөмкин.

2. "Үсемлекләр үсә торган җир, туфрак, коры җир" ассоциатив-семантик төркеме.

Табышмакларда әлеге төркем күпчелекне алып тора. *Җир* лексемасы, беренче чиратта, җир өсте, җирнең өске катламы мәгънәсендә киң кулланыла. Аеруча яшелчә, үлән турындагы табышмакларда *җир* лексемасы шундый ассоциация тудыра, чөнки үсемлек дөньясы турыдан-туры җир белән бәйле һәм табышмак төзегәндә дә авторлар аларны җир белән бәйләргә тырыша:

Түгәрәк, түгәрәк шар кебек,
Кызыл, кызыл, кан кебек;
Башы *җиргә* салынган,
Аңа кызлар ялынган (җир җиләге).

Күп кенә табышмакларда *җир асты* сүзтезмәсе очрый. Бу сүзтезмә мәкаль-әйтемнәрдә үзенә бер төрле күзаллаулар, борынгы ышанулар белән бәйле булса һәм шундый ассоциация тудырса да, табышмакларда ул ниндидер җир асты дөньясы булудан бигрәк, туфрак асты, казылган җир асты буларак күзаллана. Һәм әлеге

сүзтезмә, нигездә, яшелчә турындагы табышмакларда урын ала, чөнки яшелчәләрнең күбесенең тамыразыгы җирдә, туфрак астында бит:

*Җир астында* кызыл әтәч (чөгендер).

Кайбер табышмакларда *җир асты* белән янәшә мәгънәсе буенча аңа капма-каршы булган *җир өсте* сүзтезмәсе дә кулланыла. Бу, бәлки, табышмакның җавабы ачыграк аңлашылсын өчен дә урыналадыр:

Кызыл кызы *җир астында,*

Чәчләре *җир өстендә* (кишер).

Ашлык үстерү, ашлык җилгәрү, чәчү, уру кебек көнкүреш эшләре, яисә әлеге эшне башкару кораллары белән бәйле булган табышмакларда да *җир, туфрак* сүзләре даими кулланыла:

Тимер ат *җир* сөрә, ашарга сорамый (трактор).

Гомумән, татар халкының тормышы борын-борыннан җир, туфрак, җир эшләре белән бәйле булган, татар кешесе сөенсә дә, көенсә дә, эшләгәндә дә, ял иткәндә дә, ачуланып та, яратып та җиргә мөрәҗәгать иткән.

Күп кенә табышмакларда *җир* лексемасының шушы мәгънәдә кулланылышы *кара җир, кара туфрак, җир туфрагы, туфрак* кебек сүзтезмәләр яисә сүзләр аша да аңлашылырга мөмкин:

Югары менсәм мәрвәри,

Түбән төшсәм мәрвәри;

Мәрвәринең яфрагы

Кара *җирнең* туфрагы (ашлык җилгәрү).

Әлеге табышмакларның җаваплары шактый тирән яшерелгән, аларны табу өчен баладан логик фикер йөртә алу сәләтенең бик көчле булуы таләп итеlә. Биредә табышмакның җавабы, нигездә, табышмакта урын алган *җир, туфрак* сүзләре белән генә бәйле дисәк тә дөрес булыр.

Ә менә су хайваннары, балыклар турындагы табышмакларда урын алган *җир* сүзе, уңдырышлы җир булудан бигрәк, коры җир буларак күзаллана. Һәм еш кына ул *коры* эпитеты белән бирелә дә:

Суда туды, *җирдә* үлде (балык).

3. "Билгесезлек, билгесез, яшерен нәрсә" ассоциатив-семантик төркеме.

Табышмакларның байтагында *җир* сүзе билгесез урынны аңлату өчен кулланылган:

Бер *җирдә* бар, ди, бер агач,

Агачы саен бар, ди, ботак,

Ботагы саен бар, ди, йомырка (борчак).

Кайчак табышмакның җавабы җиңел генә табылмасын, аңлашылмасын өчен дә табышмактагы теге яки бу төшенчәнең чын атамасын яшереп, *җир* лексемасы белән атыйлар:

Ак *җир*, кара тап,

Нәрсә булыр, уйлап тап (китап).

Әлеге табышмакларда халкыбыз *ак кәгазь, ак бит* кебек сүзләрне турыдан-туры атамыйча, *ак җир* лексемасы астына яшереп бирә.

4. "Урын, ара" ассоциатив-семантик төркеме.

Мәкаль-әйтемнәрдәге кебек үк биредә дә *җир* сүзе күп очракта урынны, аерым төшне белдерү өчен кулланыла. Әмма шунысын да искәртергә кирәк: телебездә урын мәгънәсе үзе үк шактый киң төшенчәгә ия. Шуңа бәйле рәвештә *җир* лексемасы да контекстка карап, урын мәгънәсенең төрле төсмерләрен белдерергә мөмкин. Мәсәлән, түбәндәге табышмакларда *җир* сүзе безгә теге яки бу затның, әйбернең туктап тору, утырып тору, урнашкан урыны буларак ассоцияләнә:

Утырган *җирем* – уй чокыр,

Баскан *җирем* – бай чокыр,

Бер кулымда – кыптырым,

Бер кулымда – сыптырым (ияр, өзәңге, тезген, камчы).

Табышмакларның бер өлешендә кешенең, хайван-кошларның, яисә теге яки бу әйбернең барып, очып җитү, туктау, куну урыны да еш кына *җир* лексемасы белән бирелә:

Утырдым – киттем, типкәм белән типтем,

Кирәк *җиргә* җиттем (атка атланган кеше).

Бу табышмаклардагы *җир* сүзен бернинди икеләнүсез *урын* лексемасы белән алыштырып булыр иде, чөнки ул әлеге очракта чын мәгънәсендә бездә бары тик урын ассоциясен генә тудыра. Мондый мисаллар табышмакларда байтак очрый:

Билен биш *җирдән* буган,

Үзе урманда туган (гөбе).

Кайбер очракларда теге яки бу әйбернең, кеше гәүдәсенең аерым бер төшен, органын белдерү өчен дә *җир* сүзе кулланылырга мөмкин:

Тызлый да бызлый, үпкән *җире* сызлый (бал корты).

Биредә әби-бабаларыбыз озын-озак сөйләп тормаган, кыска гына итеп, күп мәгънә сыйдырышлы сүз – *җир* лексемасы белән атаган.

5. "Мифик күзаллаулар белән бәйле" ассоциатив-семантик төркем.

Әлеге төркемгә керүче табышмаклар бик аз. Борынгы бабаларыбыз төрле җир асты, җир өсте тәңреләренә, төрле ияләргә ышанып яшәгәннәр һәм бу халык авыз иҗатына да үз эзен салып калдырган. Мәсәлән, түбәндәге табышмакларда без албасты, ялман дигән мифологик геройлар белән очрашабыз,хәтта җир дә алардан курка. Мондый эчтәлектәге табышмаклар, әлбәттә, юктан гына барлыкка килми, аларда халкыбызның ышанулары урын ала:

Албасты күкне басты,

Кояшны йотты,

*Җир* посты,

Авызын ачмый албастыны упты (болыт, яңгыр, җир).

Гомумән алганда, *җир* концепты табышмакларда шактый киң мәгънәгә ия, чөнки безнең ата-бабаларыбызның, хәтта барлык төрки халыкларның тарихи тамырлары җир белән бәйле булган.

Әдәбият

Татар халык иҗаты: Табышмаклар. – Казан, 1977. – 584 б.